МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.11.2019 г.Казань № 1038

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 20 декабрендә 6273 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 13 ноябрендәге 625 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 625 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.11.2015 № 839, 07.06.2016 № 317, 27.09.2018 № 907, 31.05.2019 № 414 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт,

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.11.2014 № 625 боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.11.2019 № 1038 боерыгы редакциясендә) расланды

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә бердәмлекне, тулылык, сыйфат һәм дәүләт хезмәтеннән (алга таба – дәүләт хезмәте) тигез дәрәҗәдә файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатында эшләнде.

1.2. Регламент дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре – халыкның мәшгульлек үзәкләренең Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда гамәлләренең (административ процедураларның) эзлеклелеген билгели.

1.3. Гариза бирүчеләр – Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.4. Мәшгульлек үзәгенең эш графигы: шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен. Эш сәгатьләре мәшгульлек үзәгенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә туры китереп билгеләнде.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гражданнардан гаризалар кабул итү графигы халыкның мәшгульлек үзәгенең эш графигы белән туры килә.

1.4.1. Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

1.5. Халыкның мәшгульлек үзәгенең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почтасы адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.6. Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайты адресы: http://mtsz.tatarstan.ru, электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

1.7. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлык холлында, гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында; халыкның мәшгульлек үзәге сайтында;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы), шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр (алга таба – КФҮ) аша;

«Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки Министрлыкның (843)557-21-13 белешмә телефоны буенча);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).

5) КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткәндә.

1.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүмат гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык, халыкның мәшгульлек үзәге биналарында мәгълүмат стендларында дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1,1, 1.4, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 статья);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3448 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)(алга таба – 149-ФЗ номерлы федераль закон);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3451 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 53, 7598 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 14, 1652 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 статья) (алга таба – 601 номерлы указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт һәм мәшгульлек буенча федераль хезмәт турында нигезләмә раслау турында» 2004 елның 30 июнендәге 324 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 28, 2901 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3169 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы (Российская газета, 2011, 2 февраль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшчәнлек (һөнәр), эшкә урнашу өлкәсен сайлау, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 23 августындагы 380н номерлы боерыгы (Российская газета, 2013, 13 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 380н номерлы стандарт);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек органнары һәм медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 14 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201512140027);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август, басылып чыгу номеры: 0001201708010058);

«Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024) (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган тәртип);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениелщре тәкъдиме буенча башка җирлеккә һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем алу өчен юллануларына бәйле рәвештә эшсез гражданнарга финанс ярдәмен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 16 мартындагы 228 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары җентыгы» журналы, 2012, № 32, 1000 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.9. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

- техник хата дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

Гариза формасы 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасында эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри ориентация бирү | Халыкның мәшгульлеге турында законның 7.1-1 статьясының 1 өлешендәге 8 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесе (халыкның мәшгульлек үзәге).<br>Халыкның мәшгульлек үзәге Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт хезмәте күрсәтелүен гамәлгә ашыра.<br>Килешү нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан җәлеп ителә торган, кирәкле белемнәргә һәм эш тәҗрибәсенә ия булган, гражданнарның һөнәри ориентациясендә кулланыла торган методларга, методикаларга, гражданнарны һөнәри ориентацияләүнең тренинглар һәм технологияләр формаларына ия булган белгечләр яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтү хокукына ия булган оешмалар тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү (дәүләт хезмәтенең бер өлешен күрсәтү) рөхсәт ителә | 380н номерлы стандартның 11.1 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып гариза | 380н номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсенә тасвирлама | бирүчегә 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү яки әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар бирү тора | стандартның 16 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Гражданнарга, тест (анкета) уздыру һәм тренинг уздыру вакытын исәпкә алмыйча, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты 60 минуттан артык булырга тиеш түгел. | 380н номерлы стандартның 15 п.; |
| | Инвалидлар категориясенә караучы гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, үз инициативасы белән инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын (алга таба – ТАХП) яки медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениедән билгеләнгән тәртиптә бирелгән ТАХП өземтә (инвалидлар категориясенә караучы гражданнар өчен) гариза бирүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтәсе булмаганда, гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне тәшкил итә. | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 ел, 16 ноябрь, 872 номерлы боерыгына 3 нче кушымтаның 1 пункты; |
| | Гариза бирүчеләр шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, халыкның мәшгульлек үзәгенә яки КФҮ, читтән торып эшләү урынына беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә. | 380н номерлы Стандартның 7 пункты; |
| | Гариза бирүчеләр КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гариза КФҮ килгән | 380н номерлы Стандартның 8 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br><br>Дәүләт хезмәте халыкның мәшгульлек үзәгенә алдан язылу нигезендә күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү датасын һәм вакытын килештерү халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган. | <br><br>380н номерлы стандартның 9 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасы (алга таба – гариза) яисә дәүләт хезмәте күрсәтү турында халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча бирелгән тәкъдим белән ризалыгы (алга таба – тәкъдим).<br><br>Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы | 380н номерлы стандартның 5 пункты;<br><br><br><br><br><br>380н номерлы стандартның 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Порталында урнаштырылган.<br>Гариза бирүчеләр өчен гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тудырыла: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яисә гаризаны КФҮ, читтәге эш урыны аша тапшыру юлы белән. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәгеләрне үз эченә алучы документлар алына:<br>ТАХП өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:<br>эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);<br>организмының бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.<br>Әлеге белешмәләр аларны МСЭ мөстәкыйль җибәрмәгән очракта, 486 н номерлы боерыкка 1 нче кушымтаның 14 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә соратыла.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә | 380н номерлы стандартның 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br><br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларны тапшырмау тора. | 380н номерлы Стандартның 5, 13 пунктлары |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 210-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы;<br>Халык мәшгульлеге турындагы законның 15 статьясының 3 пункты;<br>380н номерлы стандартның 12 пункты |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Гариза бирүчеләр белән халыкның мәшгульлек үзәгенә яки КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, яисә почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.<br>Гариза бирүченең мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килешенгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел | 601 номерлы указ;<br>380н номерлыстандартның 8 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гаризаны теркәү дигәндә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның (физик затларның, эш бирүчеләрнең) электрон регистрына, хисап язмасының теркәү номерын биреп, гариза бирүче (гражданинның, эш бирүченең) тапшырган документлардагы белешмәләрне кертү күз алдында тотыла.<br>Гариза бирүчеләр өчен гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тудырыла: халыкның мәшгульлек үзәгенә яки КФҮгә, КФҮ читтән торып эшләү урынына шәхсән, факсималь элемтә чараларын кулланып яисә электрон формада, шул исәптән Татарстан Республикасы | Халык мәшгульлеге турында законның 16.1 статьясындагы 2 пункты<br><br>380н номерлы стандартның 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | порталыннан файдаланып мөрәҗәгать иткәндә.<br>Гариза бирүченең (гражданинның) соравы буенча гаризаны кабул итү көне һәм хисап язмасының теркәү номеры турында белешмәләр булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү бүлмәләре биналарның аерым керү юлы белән җиһазландырылган аскы катларында яки аерым торучы биналарда урнаша.<br>Хезмәт күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү һәм чыгу өзлексез токның автоном чыганаклары белән тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда күренә торган җирдә янгын сүндерү чараларының урнашу һәм килүчеләрне һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгечләрен эвакуацияләү юллары схемасы урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннар тавыш белән мәгълүмат җиткерү һәм электрон хәбәр итү системалары белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда килүчеләргә файдалану мөмкинлеге булган иҗтимагый файдалану урыннарын (бәдрәфләрне) һәм өске кием-салымны саклау урыннарын җиһазлау күздә тотыла.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең эш урыны | ТР Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган тәртип |

| | | |
|---|---|---|
| | фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән дивар элмә тактасы һәм өстәл табличкасы белән җиһазландырыла. Халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси күкрәк тамгасы (бейдж) белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, шулай ук Интернет-ресурсларда да (Татарстан Республикасы порталында) урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны рәсмиләштерү гражданнарның бу мәгълүматны оптималь күрү һәм ишетү ягыннан кабул итүенә туры килергә тиеш. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мәгълүматның гариза бирүче өчен хосусый яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү формасында мөмкинлекле булуы (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларыннан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү, Татарстан Республикасы Порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән). | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^{1}$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | 2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле гариза формаларын һәм башка документларны алу мөмкинлеген тәэмин итү, шул исәптән аларның күчермәләрен алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән.<br>3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытын саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсеннән, электрон почтадан файдаланып, Татарстан Республикасы порталы, КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында.<br>5. Инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>6. Инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәкләрендә халык мәшгульлеге турында Россия Федерациясе законнарындагымәҗбүри таләпләрнең, әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүе.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын саклау.<br>3. Әлеге Регламентта билгеләнгән административ | |

| | | |
|---|---|---|
| | процедураларның эзлеклелеген саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә баш тартуларның нигезле булуы.<br>5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Гариза бирүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән багланышлары саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Үзара хезмәттәшлек итү дәвамлылыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>- КФҮләрдә, КФҮләрнең читтәге эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Гариза бирүче КФҮ, КФҮ читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, КФҮ алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | Әлеге Административ регламентның 3.1.1 пунктында, 1-7, 11-12 пунктчаларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә гамәлгә | 380н номерлы стандартның 17 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | ашыру рөхсәт ителә.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] статьясы һәм 21[2] статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] статьясы |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрында булган гариза бирүче турындагы белешмәләргә анализ, яки халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрына гариза бирүче турында түбәндәге мәгълүматларны тәгаенләү һәм кертү:

һөнәре (белгечлеге), квалификациясе, вазыйфасы, эшчәнлек төре;

һөнәри эшчәнлек алып бару мөмкинлеген бирә торган белемнәре, осталыклары, күнекмәләре һәм компетенцияләре, аларның дәрәҗәсе һәм күләме;

эшчәнлек аерым төрләрен, белем алуны гамәлгә ашыруда медицина күрсәтүләре яки медицина каршылыклары булу;

2) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, һөнәри ориентация юнәлешләре турында мәгълүмат җиткерү;

3) гариза бирүчене гражданнарны һөнәри ориентацияләүдә кулланыла торган методлар, методикалар, гражданинның һөнәри ориентациясе буенча тренинглар һәм технологияләр формалары белән таныштыру;

4) гариза бирүчегә гражданнарны һөнәри ориентацияләүдә кулланыла торган методикалар буенча тест (анкета) узарга, тест узу ысулын сайларга тәкъдим итү (тиешле программа тәэминатыннан файдаланып яки язмача формада);

5) гариза бирүче сайлаган ысул нигезендә тест (анкета) уздыру;

6) гражданинга тест (анкета) уздыру материалларын эшкәртү;

7) гариза бирүчегә һөнәри ориентация буенча тренинг узарга тәкъдим итү;

8) гражданин риза булганда, һөнәри ориентация буенча тренинг уздыру;

9) һөнәри ориентация буенча тренинг йомгакларын ясау һәм аның нәтиҗәләре турында фикер алышу;

10) тест һәм тренинг уздыру нәтиҗәләре нигезендә интервью (әңгәмә) методларыннан кулланып, һөнәри консультация уздыру;

11) дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим ителә торган, билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эшләр башкару мөмкинлеген бирә торган һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек һәм компетенцияләр төрләрен, гариза бирүче өчен гамәлгә ашыруы мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча мөмкин юнәлешләрне үз эченә алган бәяләмәне (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә) рәсмиләштерү һәм гражданинга тапшыру (җибәрү); дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең бер нөсхәсен халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның шәхси эшенә теркәп кую;

12) административ процедураларны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәләрен халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү;

13) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик

хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

3.2. Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрында булган гариза бирүче турындагы белешмәләргә анализ, гариза тутырганда ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен нигез булып гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе яисә аның халыкның мәшгульлек үзәге биргән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалыгы тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча гражданиннан дәүләт хезмәтеннән файдалануга гаризаны кабул итә (кирәк булган очракта тутырганда ярдәм итә) яки 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән килешүен рәсмиләштерә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гаризаны КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша, почта элемтәсе ярдәмендә, факсимиль элемтә чараларыннан яки электрон формада, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы Порталыннан файдаланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәргән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләрнең булу-булмавын карый. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алдан язылу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Гариза бирүчеләр белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, яисә почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплекска гариза бирүче турындагы белешмәләрне эзләү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә тиешле исәпкә алу документлары бланкларын таба;

гариза бирүченең эшсез зат сыйфатында халыкның мәшгульлек үзәгендә исәптә тору-тормавын, гариза бирүченең инвалидлар категориясенә карау-карамавын ачыклый;

халыкның мәшгульлек үзәгенең гамәлдәге архивыннан гариза бирүченең шәхси эшен ала (булган очракта).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә баш тарту нигезләренең булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада баш тарту турында язмача карар рәсмиләштерә һәм әлеге карар белән гариза бирүчене кул куйдыртып таныштыра. Баш тарту турындагы карарның бер нөсхәсе гариза бирүчегә бирелә, баш тарту турында карарның икенче нөсхәсе гариза бирүченең шәхси эшенә теркәлә.

Әгәр гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән кул куйдыртып таныштырылмаса, аның адресына дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында язмача хәбәр

җибәрелә.

Гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгате буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәлү номеры турында белешмәләре булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин.

Инвалидлар категориясенә караучы гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы белән МСЭ тарафыннан бирелгән ТАХП тапшырылмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 ел, 16 ноябрь, 872н номерлы боерыгы нигезендә, халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында организмының бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның хезмәт һәм һөнәри эшчәнлеге буенча киңәш ителә торган төрләрне сайлау өчен электрон формада белешмәләр (ТАХП өземтә) ала.

Процедураларны башкару срогы:

әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап 10 минуттан артмаган чорда гамәлгә ашырыла, әгәр гариза бирүче инвалидлар категориясенә карамаса, яки әгәр гариза бирүче инвалидлар категориясенә караса һәм үз инициативасы белән ТАХП тапшырылган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтәсе булган очракта;

әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр инвалидлар категориясенә караучы гражданин үз инициативасы белән ТАХП тапшырмаган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтәсе булмаса.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан дәүләт хезмәтеннән файдалануга кабул ителгән гариза яки дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдименә карата гариза бирүчедән рәсмиләштерелгән ризалык, гариза бирүчегә телдән (язмача) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү, гариза бирүчегә кайтарып бирелгән документлар, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында язмача хәбәр итү, белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать, электрон формада алынган белешмәләр.

3.3. Гариза бирүчегә гражданнарны профессиональ ориентацияләгәндә кулланыла торган методикалар буенча тест (анкета) узарга киңәш итү, тест үткәрү ысулын (тиешле программа тәэминатыннан файдаланып яки язма рәвештә (тест бланкларын, анкеталарны тутыру юлы белән) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү формасын (төркемле яки шәхси) сайларга тәкъдим итү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә тест (анкета) үтү формасын сайларга тәкъдим итә – тиешле программа-техник комплекс һәм махсус җиһазлар кулланып яки гади язма рәвештә (тест бланкларын, анкеталарны тутыру юлы белән).

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең тест (анкета) үтүгә ризалыгы (аларны узудан баш тартуы), ә риза булган очракта – тест (анкета) үткәрү формасын билгеләү.

3.4. Үткәрү ысулы буенча гариза бирүче ихтыярын исәпкә алган методикалар буенча тест (анкета) үткәрү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә үзе сайлаган форма буенча тест (анкета) үткәрә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 40 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тест (анкета) үткәрү.

3.5. Гариза бирүченең тест (анкета) материалларын эшкәртү, тест (анкета) нәтиҗәләрен анализлау.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

кулланыла торган методикалар нигезендә гариза бирүченең тест (анкета) материалларын эшкәртә;

тест (анкета) нәтиҗәләрен анализлый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үткәрелгән тест (анкета) буенча бәяләмә.

3.6. Гариза бирүчене тест (анкета) нәтиҗәләре белән таныштыру.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчене тест (анкета) нәтиҗәләре белән таныштыра.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Гариза бирүчене тест (анкета) нәтиҗәләре белән таныштыру.

3.7. Гариза бирүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре турында фикер алышу һәм гариза бирүчене ихтимал һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр, шулай ук һөнәргә уку ихтималы һәм (яки) аның мөмкинлекләренә, физик һәм (яки) психологик сыйфатларына, сәламәтлегенең чикләнгән мөмкинлекләренә аеруча туры килә торган өстәмә һөнәри белем алуның ихтимал юнәлешләре белән таныштыру.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

гариза бирүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре буенча фикер алыша.

гариза бирүчене һөнәри эшчәнлекнең мөмкин юнәлешләре, эш белән тәэмин итү төрләре һәм гражданинның шәхси сыйфатларына туры килә торган һөнәрләр (белгечлекләр) белән таныштыра;

гариза бирүченең ихтыяҗларына һәм мөмкинлекләренә иң туры килә торган һөнәри эшчәнлек юнәлешләрен, эш белән тәэмин итү һәм һөнәр (белгечлек) төрләрен ачыклый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре буенча фикер алышу, гариза бирүчене һөнәри эшчәнлекнең мөмкин булган юнәлешләре, эш белән тәэмин итү һәм компетенцияләр белән таныштыру.

3.8. Гариза бирүчене хезмәт базарында булган ихтыяҗ һәм тәкъдим белән, хезмәт ресурсларының фаразланган балансы, хезмәт базарының һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча фаразланган ихтыяҗы белән таныштыру.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә эшкә алучы затларның сайланган һөнәрләр (белгечлекләр), хезмәт базарында тотрыклы сорала

торган һөнәрләр (белгечлекләр) буенча ихтыяҗлары, квалификация таләпләре, алар файдалана торган икътисад өлкәләре, буш эш урыннарын (вакантлы вазыйфаларны) биләү өчен кандидатураларга карата эш бирүчеләрнең таләпләре, хезмәт шартлары, ихтимал һөнәри-квалификацияле үсеш мөмкинлекләре, шул исәптән башка җирлектә дә, эшкә урнашу перспективалары турында мәгълүмат бирә, туры килә торган эш эзләүне дәвам иттерергә тәкъдим итә һәм гариза бирүчегә туры килә торган эш эзләүдә гражданнарга булышлык күрсәтә торган функцияне гамәлгә ашыручы халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчене Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы хәл белән таныштыру.

3.9. Гариза бирүчене түбәндәгеләр белән таныштыру:

Эшләрнең һәм һөнәрләрнең бердәм тариф-квалификация белешмәлегендә һәм Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлегендә каралган һөнәри стандартлар, таләпләр белән яки федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә торган, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре белән, гражданин сайлаган һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек һәм компетенцияләрнең билгеле бер өлкәсендә һөнәри эшчәнлекне алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирә торган төрләре турында мәгълүматларны үз эченә алган профессиограммалар, видеофильмнар һәм (яки) аудиоязмалар белән;

гариза бирүче сайлаган һөнәргә уку һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алу юнәлешләре буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары, мәгариф стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф программалары, үрнәк төп мәгариф программалары, өстәмә һөнәри программалар белән, мәгариф оешмалары, мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешмалар, һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеге белән, тиешле һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча квалификацияне, максатчан кабул итү һәм максатчан укыту турында килешү төзү шартларын күрсәтеп, һәм сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгәннәргә белем алу өчен махсус шартлар тудырылган мәгариф оешмалары исемлеге белән (зарурлык булганда).

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

гариза бирүчене Эшләрнең һәм һөнәрләрнең бердәм тариф-квалификация белешмәлегендә һәм Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлегендә каралган һөнәри стандартлар яки федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә торган, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре белән;

гариза бирүче сайлаган һөнәргә уку һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алу юнәлешләре буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары, мәгариф стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф программалары, үрнәк төп мәгариф программалары, өстәмә һөнәри программалар белән;

мәгариф оешмалары, мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешмалар, һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеге белән, тиешле һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча квалификацияне, максатчан кабул итү һәм максатчан укыту турында килешү төзү шартларын күрсәтеп, һәм сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгәннәргә белем алу өчен махсус шартлар тудырылган мәгариф оешмалары исемлеге белән (зарурлык булганда) таныштыра;

гариза бирүчегә ихтимал һөнәри эшчәнлек юнәлеше, белеме, квалификация дәрәҗәсе, мәшгульлек төре һәм һөнәре (белгечлеге) буенча сәламәтлегендә булган чикләмәләре һәм медицина каршылыклары турында, социаль-хезмәт эшчәнлегенең башка факторлары турында мәгълүмат бирә; гражданинны ул сайлаган һөнәри эшчәнлек юнәлешләре, мәшгульлек төрләре һәм һөнәрләр (белгечлекләр) турында мәгълүматны үз эченә алган профессиограммалар, видеофильмнар һәм (яки) аудиоязмалар белән таныштыра.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 6 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчене Эшләрнең һәм һөнәрләрнең бердәм тариф-квалификация белешмәлегендә һәм Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлегендә каралган һөнәри стандартлар яки федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә торган, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре белән таныштыру.

3.10. Эшкә, эш эзләүгә, һөнәри эшчәнлек төрен сайлауга, һөнәри белем алуга һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алуга мотивация дәрәҗәсе түбән булган гариза бирүчегә һөнәри ориентация буенча тренинг узарга һәм тренинг формасын сайларга киңәш итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшкә, эш эзләүгә, һөнәри эшчәнлек төрен сайлауга, һөнәри белем алуга һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алуга мотивация дәрәҗәсе түбән булган гариза бирүчегә һөнәри ориентация буенча тренинг узарга һәм тренинг формасын сайларга киңәш итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең тренинг үтүгә ризалыгы (риза булмавы), ә риза булган очракта – тренинг үткәрү формасын билгеләү.

3.11. Эшкә, эш эзләүгә, һөнәри эшчәнлек төрен сайлауга, һөнәри белем алуга һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алуга мотивация дәрәҗәсе түбән булган гариза бирүче белән ул сайланган тренинг формасы буенча һөнәри ориентация буенча тренинг уздыру.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүче ризалыгы белән сайлап алынган форма буенча тренинг үткәрә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 90 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең тренинг узуы.

3.12. Һөнәри ориентация буенча тренингларга йомгак ясау һәм нәтиҗәләр хакында фикер алышу.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече уздырылган тренингка йомгак ясый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданин белән тернинг йомгаклары турында фикер алышу.

3.12.1. Тест һәм тренинг уздыру нәтиҗәләре нигезендә интервью (әңгәмә) методларын кулланып, һөнәри консультация уздыру.

һөнәри (эш, хезмәт) эшчәнлеге төрен (алга таба – һөнәри эшчәнлек), һөнәргә уку яки өстәмә һөнәри белем алу өчен һөнәр (белгечлек) төрен сайлауга мотивацияләү факторларың; сайлана торган һөнәр буенча хезмәтнең эчтәлеге һәм шартлары турында белемнәрне; һөнәри эшчәнлекне алып бару мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәрне, сәләтләрне һәм күнекмәләрне, компетенцияләр дәрәҗәсенә һәм күләменә карата таләпләрне яки конкрет һөнәр яки белгечлек буенча эшләр башкару, һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешү ысулларын; гражданинның һөнәри омтылышларын, өстенлек бирүләрен, мөмкинлекләрен, физик һәм (яки) психологик сыйфатларын; Эшләргә һәм эшче һөнәрләргә карата бердәм тариф-квалификация белешмәлегендә һәм Эш бирүчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлегендәге таләпләргә яки федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә торган, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен ачыклау;

гариза бирүчене тест (анкета) нәтиҗәләре белән таныштыру;

гариза бирүчене ихтимал һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр, шулай ук һөнәргә уку ихтималы һәм (яки) аның мөмкинлекләренә, физик һәм (яки) психологик сыйфатларына, сәламәтлегенең чикләнгән мөмкинлекләренә аеруча туры килә торган өстәмә һөнәри белем алуның ихтимал юнәлешләре белән таныштыру;

гариза бирүчене хезмәт базарында булган ихтыяҗ һәм тәкъдим белән, хезмәт ресурсларының фаразланган балансы, хезмәт базарының һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча фаразланган ихтыяҗы белән таныштыру;

гариза бирүчене Эшләрнең һәм һөнәрләрнең бердәм тариф-квалификация белешмәлегендә һәм Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлегендә каралган һөнәри стандартлар, таләпләр белән яки федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә торган, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре белән, гражданин сайлаган һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек һәм компетенцияләрнең билгеле бер өлкәсендә һөнәри эшчәнлекне алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирә торган төрләре турында мәгълүматларны үз эченә алган профессиограммалар, видеофильмнар һәм (яки) аудиоязмалар белән таныштыру;

гариза бирүчене, тиешле һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча бирелә торган квалификацияне һәм максатчан кабул итү һәм максатчан укыту турында килешү төзү шартларын күрсәтеп, гражданин сайлаган һөнәри

белем алу һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алу юнәлешләре буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары, белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф программалары, якынча төп белем бирү программалары, өстәмә һөнәри белем бирү программалары белән, мәгариф оешмаларының, белем бирүне гамәлгә ашыра торган оешмаларның, һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның исемлеге (алга таба – белем бирү оешмалары исемлеге) белән, шулай ук сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен белем алуда махсус шартлар тудырылган белем бирү оешмаларының исемлеге (кирәк булганда) белән таныштыру;

һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр исемлеген, аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүче һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешергә мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча ихтимал юнәлешләрне үз эченә алган тәкъдимнәрне әзерләү һәм гариза бирүчегә тапшыру;

тәкъдимнәр турында гариза бирүче белән фикер алышу һәм аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүченең гамәл кылу юнәлешләрен билгеләү.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрен һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияне сайлавы.

3.13. һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр исемлеген, аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүче һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешергә мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча ихтимал юнәлешләрне үз эченә алган тәкъдимнәрне әзерләү һәм гариза бирүчегә тапшыру.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр исемлеген, аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүче һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешергә мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча ихтимал юнәлешләрне үз эченә алган тәкъдимнәрне әзерли.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 4 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: уңышлы һөнәри эшчәнлек юнәлешләре буенча бирелгән тәкъдим.

3.14. Тәкъдимнәр турында гариза бирүче белән фикер алышу һәм аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүченең гамәл кылу юнәлешләрен билгеләү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

гариза бирүчегә тәкъдим ителә торган һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек

төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр, аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүче һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешергә мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча ихтимал юнәлешләрне үз эченә алган тәкъдимнәр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр исемлеге буенча фикер алыша.

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрын үз эченә алган программа-техник комплекста административ процедура нәтиҗәсен терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче тарафыннан сайлап алынган һөнәри эшчәнлек юнәлеше.

3.15. Һөнәри эшчәнлек, мәшгульлек төрләре һәм билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эш башкару мөмкинлеген бирүче компетенцияләр исемлеген, аларны гамәлгә ашырганда гариза бирүче һөнәри яки эшкуарлык эшчәнлегендә уңышка ирешергә мөмкин булган һөнәргә уку һәм (яки) һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу буенча ихтимал юнәлешләрне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәне рәсмиләштерү һәм гариза бирүчегә тапшыру (җибәрү).

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә әзерли, гражданинны кул куйдыртып аның белән таныштыра һәм гражданинга бәяләмәне тапшыра (җибәрә), бәяләмәнең икенче нөсхәсен шәхси эшкә теркәп куя.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) бәяләмә, бәяләмәнең гариза бирүченең шәхси эшенә теркәлгән икенче нөсхәсе.

3.16. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәләрен халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрын үз эченә алган программа-техник комплекста дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен терки;

дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затның шәхси эшен халыкның мәшгульлек үзәгенең агымдагы архивына тапшыра.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрына кертелгән административ процедураларның нәтиҗәләре.

3.17. Кирәк булган очракта, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр һәм дәүләт контрактлары нигезендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, халыкның мәшгульлек үзәге

тарафыннан җәлеп ителә торган, тиешле хезмәтләр күрсәтүче белгечләрне һәм (яки) оешмаларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашуга җәлеп итү рөхсәт ителә.

Җәлеп ителгән белгечләр һәм (яки) җәлеп ителгән оешмаларның белгечләре кирәкле белемнәр һәм эш тәҗрибәсенә ия булырга, гражданнарга хезмәт базарында һөнәри ориентация биргәндә кулланыла торган алымнарны һәм методикаларны белергә тиеш.

3.18. Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерә;

- гариза бирүчегә аның гаризасында күрсәтелгән ысул белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне халыкның мәшгульлек үзәге директоры яки аның вәкаләтле хезмәткәре башкара.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне агымдагы тикшерүдә тоту халыкның мәшгульлек хезмәте белгеченең әлеге Административ регламентны, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы белән расланган Халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын, аларда булган белешмәләрне бир тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп, алып бару тәртибен, дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затларны исәпкә алу документациясе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген регламентлаучы башка документларның бланкларын тутыруга, алып баруга һәм саклауга карата таләпләрне саклавына һәм үтәвенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшерүләрне гамәлгә ашыру ешлыгы халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан билгеләнә.

4.3. Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тотуны, эшсез гражданнарга социаль

ярдәм күрсәтү өлешендәге дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүенә күзәтчелек һәм контроль буенча вәкаләтләрне үтәү кысаларында Министрлык гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) урынга чыгып (документар) тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрләре, халыкның мәшгульлек үзәге һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул итәлә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының (белгеченең) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәгенең, халыкның мәшгульлек үзәге вазыйфаи затының (белгеченең) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны, ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны гариза бирүчедән таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfcl6.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

Шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турында мәгълүмат халыкның мәшгульлек хезмәте бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә

почта буенча язмача формада, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында да, мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан гражданинның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

Халыкның мәшгульлек үзәге, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы гариза бирүчегә язмача яисә, аның ихтыяры белән, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган

(учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты (белгече) яки дәүләт хезмәткәре, КФҮ, КФҮ хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Гариза бирүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

6.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http ://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

КФҮ белгече гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – халыкның мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша КФҮгә язмача тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

КФҮ белгече халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

РӘВЕШЕ

«__________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин, ________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ___________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)
әлеге техник хатаны төзәтүгез турында сорыйм_____________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________, Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында 20___ елның «___»________________ бирелгән бәяләмәне рәсмиләштерелгәндә җибәрелгән.

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән тәкъдимне алырга риза

_____________________________________________________________________
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)
«__» __________ 20__ ел. __________________ ____________________________
(гариза бирүченең имзасы) (тулы имза)

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

үрнәк

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта) | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

РӘВЕШЕ

«________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында

КАРАР

«___» __________ 20__ ел, № ______

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20__ елның «__»______________ ____ номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.8 пункты нигезендә ___________________________ дәүләт хезмәтен күрсәтүдән БАШ ТАРТЫРГА.

Баш тарту сәбәбе:

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече ___________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), имза)

Карар белән таныштым _____________________ ________ _____________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза) (көне, ае, елы)

Карарны алдым_______________________________________________________

(Гражданинның, эш бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«__» _____________ 20__ ел.

Язмача хәбәр җибәрелде <*> ____________ № __________________

(көне, ае, елы) (хезмәткәрнең вазыйфасы, Ф.И.А. (соңгысы - булган очракта), имзасы)

-------------------------------

<*> - белдерү гражданин карар белән кул куеп танышмаган очракта җибәрелә.

«Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелүен тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| т/с | Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Урнашкан урын адресы, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай шәһәре, Төзүчеләр урамы, 10 Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| 2 | «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.п., Романов урамы, 6 Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| 3 | «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 61 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| 4 | «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск эшчеләр поселогы, Ленин урамы, 87 Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| 5 | «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак авылы, Совет урамы, 8 Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| 6 | «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-45-47 | 423452, Әлмәт шәһәре, Герцен урамы, 86а Czn.Almet@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас авылы, Шоссейная урамы, 5 Czn.Apastovo@tatar.ru |
| 8 | «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш.т.п., Банк урамы, 6в Centr.Arskiy@tatar.ru |
| 9 | «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 63 Czn.Atnya@tatar.ru |
| 10 | «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы шәһәре, Энгельс урамы, 56 Czn.Bavly@tatar.ru |
| 11 | «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.п., Совет урамы, 16 Czn.Baltasi@tatar.ru |
| 12 | «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-17-60 | 423230, Бөгелмә шәһәре, Октябрь урамы, 15 Czn.Bugulma@tatar.ru |
| 13 | «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-13-73 | 422430, Буа шәһәре, Р.Люксембург урамы, 157/1 Czn.Buinsk@tatar.ru |
| 14 | «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84379) 2-24-28 | 422570, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Медгородок урамы, 21 а Czn.V-uslon@tatar.ru |
| 15 | «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 2-16-17 | 422700, Биектау авылы, Центральная урамы, 7 CZN.VGora@tatar.ru |
| 16 | «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84375) 2-24-51 | 422470, Иске Чүпрәле авылы, Центральная урамы, 15 Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| 17 | «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | 423600, Алабуга шәһәре, Спас урамы, 5 Czn.Elabugi@tatar.ru |
| 18 | «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 37б Czn.Zainsk@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | 422550, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 1 Czn.Zdol@tatar.ru |
| 20 | «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-12-60 | 422330, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| 21 | «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | 422110, Кукмара шәһәре, Ворошилов урамы, 44 Czn.Kukmor@tatar.ru |
| 22 | «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84378) 2-44-54 | 422610, Лаеш шәһәре, Чернышевский урамы, 23 Laish.Czn@tatar.ru |
| 23 | «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-59-70 | 423250, Лениногорск шәһәре, Гагарин урамы, 51 Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| 24 | «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 12 Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| 25 | «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерҗе районы филиалы | директор | (85549) 2-23-57<br>(85551) 2-31-73 | 423650, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 Czn.Men@tatar.ru; 422230, Әгерҗе шәһәре, К.Маркс урамы, 11а Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| 26 | «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| 27 | «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-57-37 | 423970, Мөслим авылы, Пушкин урамы, 47 Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| 28 | «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр | директор | (8552) 52-42-68<br>(8552) | 423831, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 Chelny.CZN@tatar.ru; 423831, Яр Чаллы шәһәре, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | | 52-96-97 | Сөембикә проспекты, 47 Czn.Tukaev@tatar.ru |
| 29 | «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 (8555) 33-98-61 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Бызов урамы, 20а Czn.Nk@tatar.ru 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы эшчеләр поселогы, 2/01 Czn.Nk@tatar.ru |
| 30 | «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84348) 2-23-43 | 423190, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 93 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| 31 | «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат шәһәре, Р.С.Хәммәдиев урамы, 19 Czn.Nurlat@tatar.ru |
| 32 | «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 34 CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| 333 | «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.п., Ленин урамы, 48 Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| 34 | «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84362) 2-28-15 | 422060, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., З.Йосыпов урамы, 7 SZN.Saby@tatar.ru |
| 35 | «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман авылы, Ленин урамы, 26 Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| 36 | «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы, 21 Czn.Bolgar@tatar.ru |
| 37 | «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның | директор | (84373) 2-63-29 (8-84377) | 422370, Тәтеш шәһәре, Ирек мәйданы урамы, 45 Czn.Tetyushi@tatar.ru; 422820, Кама Тамагы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | | 2-14-67 | районы, Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс урамы, 2a Filial.K-uste@tatar.ru |
| 38 | «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче авылы, Ленин урамы, 73 Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| 39 | «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән авылы, Титов урамы, 5 Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| 40 | «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 35 Czn.chist@tatar.ru |
| 41 | «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85593) 2-60-18 | 423950, Урыссу ш.т.п., Пушкин урамы, 105/1 Czn.Yutazy@tatar.ru |
| 42 | «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | (843) 562-48-33 (843) 273-85-03 | 420034, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 81а Czn.g_Kazan@tatar.ru; 420029, Казан шәһәре, Журналистлар урамы, 13а CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| 43 | «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 537-86-00 | 420085, Казан шәһәре, 1 нче Муром урамы, 33а Czn.Avia@tatar.ru |
| 44 | «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 277-51-59 | 420049, Казан шәһәре, Качалов урамы, 77 Czn.Vah@tatar.ru |
| 45 | «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 554-77-36 | 420032, Казан шәһәре, Слободская урамы, 23 czn.kirovskiy@tatar.ru |
| 46 | «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 543-47-72 | 420039, Казан шәһәре, Гагарин урамы, 46 czn.moskovski@tatar.ru |
| 47 | «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек | директор | (843) 543-19-52 | 420044, Казан шәһәре, Ибраһимов проспекты, 41 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | үзәге» дәүләт казна учреждениесе | | | Czn.Novosavin@tatar.ru |
| 48 | «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 224-86-83 | 420101, Казан щәһәре, Бертуган Касыймовлар урамы, 22/7 CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа атылышы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Һөнәри белем бирү һәм һөнәри ориентация бүлеге башлыгы | (843) 557-20-90 | Sofya.Tonkonog@tatar.ru |